**Тема:** Бәхетле бала нинди була?

**Максат:**
1. Укучыларны "Нәрсә ул бәхет?" дигән темага уйланырга мәҗбүр итеп тормышта үз урыннарын табарга ярдәм итү.
2. Укучыларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү.
3. Бәхетне рухи тынычлыкта: Аллаһы Тәгаләгә ышанып, Ул кушканча яшәүдә, күп итеп изгелекләр кылуда икәнен аңлату.

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәсе:**

- Дөньда яшәүнең мәгънәсе- Аллаһны тану һәм Ул куйган кануннарны (законнарны) үтәү турында белү.
- Аллаһны танып, Ул кушканны үтәгән, Аның ризалыгына ирешкән кеше генә чын бәхетле була ала икәнен аңлау.
- Раббыбызның ризалыгын алуга китергән гамәлләрне белү, аларны кылырга омтылу.

**Дәреснең барышы**

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

- Социологларның тикшерүләре нәтиҗәсе буенча, Мәскәүнең олы сыйныф укучылары бер китапны һәр уңышка ирешәсе килгән яшь кеше укырга һәм кулланырга тиеш дигәннәр. Дейл Карнеги- танылган Америка язучысының "Борчылудан ничек котылырга?" дигән китабыннан бер өзекнең өчтәлегенә карап, дәреснең темасын ачыклагыз:

*Бер кеше эшен югалтып, кайгыга сабышкан: гаиләне ашатырга, квартир эчен түләргә, хәттә тишелгән аяк кимемен алыштырырлык акчасы булмаганга күрә, бүген ул үз үзенә кул салырга ныклы карар кабул иткән.*

*Лифтка кергәч, инвалид коляскасында утырган бик сөйкемле яшь кешене күргән. Егет аңа бик ачык елмаеп: "Хәерле иртә, сэр! Бүгенге иртә бигрәк матур, шулай бит?" – дип үзен юк итәргә уйлаган кешегә мәрәҗәгать иткән.*

*Бу сүзләр әлеге кешене үзенең куркыныч карарырнан кире кайтырга ярдәм иткәннәр. Бөтен күңелен әллә кайдан килгән көчле оялу хисе яулап алган: "Аяк киемне алырга акчам юк дип, үземне үтермәкче булам, ә бу яшь кешенең ботинкалар киярлек аягы булмаса да, ул ничек шат һәм барыбер бәхетле!" Тиздән эшсез кеше үзенә яхшы эш таба, әҗәтләрен түли һәм барысы да җайлана (*Дейл Карнеги "Как перестать беспокоиться и начать жить?").

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

- Димәк, бүгенге дәреснең темасы... (Шәү кече, бәхет турында- Бәхетле бала нинди була?)
- Чынлап та, бәхет байлыктамы?
- Ә инвалид кеше бәхетле була ала микән?
- Нәрсә соң ул бәхет? (Эшләгән эшеңнән тулы канәгатьләнү хисе алу (Г. Тукай. Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә; Уңыш- эштә, тормышта һ.б.)
- Укучылар, минем фикеремчә, кеше бәхетне нидә күрсә, шуңа гомере буе омтылып яши торгандыр. Бер-берегезне тыңлаганнан соң, сез бәлки "Бәхет" төшенчәсенә бүтәнчәрәк карый башларсыз, аңа ирешү өчен көрәшергә, максатчан яшәргә кирәклегенә төшенерсез.

**III.Уку мәсьәләсен чишү**

**1.** ***Уен "Мин башлыйм, син дәвам ит"***

- Бәхет белән бәйле мәкальләрне башлап җибәрәм- сез ахырын уйлап табарсыз:

- Бәхет пыяла кебек – сакламасаң ... *тиз ватыла* (немец халык мәкале).
- Бәхет атта барганда, бәхетсезлек ... *җирдә йөри* (якут).
- Акыллы кеше бәхетне ... *көтеп ятмый* (венгр).
- Бәхеткә өч нәрсә алып бара: *хезмәт, түземлелек, ныклык.*
- Тәкәбберлек беткән урында ... *бәхет башлана* (венгр).
- Бәхетле булу өчен сәламәтлек, акыл һәм ... *саф күңел кирәк* (абхаз).
- Бәхет теләктә түгел: беләктә һәм ... *йөрәктә* (абхаз).
- Бәхет үзе килми, ияреп тә йөрми – аны ... *эзләп табалар* (абхаз).
- Ызгышкан җирдән ... *бәхет кача* (абхаз).
- Бәхете ташып торса да усал кеше - ... *бәхетсез* (латин).

(Укучыларның җаваплары бераз икенче төрле булса да- аларны кире какмаска кирәк).
- Син үзең белгән кешеләр арасында кемнәрне бәхетле кеше итеп санprincipal? Ни өчен? (Укучылар җаваплары).
**-** Берәүләр**:** “Бәхет тәхеттә түгел, сатып алып булмый” - дисә, икенчеләре исә: “Акчаң булса, бәхет үзе йөгереп килә”,- диләр. Сез ничек уйлыйсыз?
(Укучылар җаваплары).

**2. Галимнәргә сүз бирәбез.**

- Көнбатышта алып барылган тикшеренүләр шуны күрсәтә: Европаның һәм Американың психиатрик хастаханәләре, нигездә, хәлле кешеләр белән тулган. Хәер, байлык кешеләрне акылдан яздырып кына калмый, бәлки аларны төшенкелекккә төшерә, үз-үзләрен үтерүгә этәрә.

Моңа бик күп мисаллар китерергә була. Күренекле язучы Джек Лондон гомере буе бай булырга омтылып яшәгән. Хыялына ирешкәч, зур үкенеч белән шуны таныган: “Мин ярлы яшәгәндә генә бәхетле идем”,- дигән. Күренекле Кодак һәм Савва Морозовлар үз-үзләренә кул салганнар. Нефть магнаты Рокфеллер коточкыч төшенкелектә үлгән. Мультимиллионер Говард Хьюз, акылыннан шашып, шәп-шәрә килеш көннәр буе яткан һәм кешенең киемен “бацилло йөртү оясы” дип исәпләгән. Бу фаҗигаләрне шәхси самолетлар да, зиннәтле йортлар да, акчалар да булдырмыйча калдыра алмый.
- Галимнәр байлык турында нинди нәтиҗә ясаганнар? (Байлык кына кешене бәхетле итә алмый, киресенчә- рухи яктан аны ярлы итә).
Укытучы: “Һәркем үзенчә бәхетле” дигән сүзләрне сез ничек аңлыйсыз?
(Укучылар җаваплары)

**3. Галимнәр уйлап тапкан “Бәхет формуласы” .**

- Күптән түгел Америка профессорлары, психологлары Дэвид Майрес һәм Эд Динер “Бәхет формуласы дүрт кисәктән тора” дип язып чыктылар. Озак вакытлар дәвамында алып барылган фәнни тикшеренүләр аркасында, алар чын бәхетле кеше түбәндәге дүрт таләпкә җавап бирергә тиеш дигән нәтиҗәгә килгәннәр:

- ***Үз-үзеңне ихтирам итәргә.*** *Андыйлар үзләренең башкалар өчен яхшы кәеф чыганагы, интеллегентлы һәм әдәпле буluларына ышаналар.*
- ***Үз-үзеңне контрольдә тота алу.*** *Андый кешеләр үзләрендә теләсә нинди проблеманы хәл итә алырлык көч барлыгын тоеп яшиләр, алар яхшы укыйлар һәм эшлиләр, стрессларга бирешмиләр.*

- ***Тормышка өмет белән карарга (оптимист булырга) кирәк.*** *Уңышка ышанган кешегә бәхет үзе юлдаш була.*
- ***Бәхетле кешеләр – тиз аралашучан, темпераментлы, аларның дуслары күп була.***

- Профессорлар фикеренчә, бәхетнең башка “деталь”ләре дә бар. Мәсәлән, АКШта дүрт гаилә парының өчесе никах җепләренең аларны бәхетлерәк итүе турында әйтә. Аллага ышанучылар да үзләрен бәхетле итеп сизәләр икән. Бәхет яшькә карамый. Моннан тыш, тикшеренүчеләр шуны күрсәтә: Бангладеш кебек хәерче илләрдә бәхет символы булып байлык тора; мул тормышлы илләрдә “бәхет акчада түгел” дип исәпләнә.

**4. Танылган кешеләр бәхет турында.**

- *“Чын бәхет, рәхәт- һәрбер кеше башка кешеләрнең ярдәменә мохтаҗ һәм сез башкаларның ярдәмен көткән шикелле алар да сезнең ярдәмегезне көтеп торганын аңлауда”* /Француз язучысы Д.Дидро/
- *“Мин үз гомеремдә чын мәгънәсендә ике бәхетсезне генә беләм: вөҗдан газабы һәм чир”.* /Рус язучысы Л. Н. Толстой/
- *“Бик күпләрне бәхетле итә алган иң бәхетле кеше була”* /Француз философы Д. Дидро/
- *“Аллаһ Раббыбыз хакыкый бәхетне дин эченә яшерде. Кем Аллаһны таныды- ул кушканнарны үтәп, тыелганнарыннан тыелып, тормышын көйләде- бәхеткә иреште”* /Җәлил хәзрәт Фазлыев/

- Сез бу фикерләр белән килешәсезме? Ни өчен? (Укучылар җаваплары)
- Кайсы фикер сезнең күңелегезгә якынрак? Ни өчен?

**IV. Төркемнәрдә эшләү, эшне тикшерү.**

**1нче бирем “*Интернетка сәяхәт*”**

- “Бәхет нәрсә ул?” дигән сорау белән Интернетка форумга кердем. Менә кайбер шуннан алынган фикерләр:
  - *Бәхет ул хәрбер туар көннең кадерен белеп яшәүдә.* /Энҗе Хайрутдинова/
  - *Бәхет ул саулык- саулык булса барда була.* /Гөлназ Галимова/
  - *Һәрбер аткан таң, барлык әгъзаларымнын сау булуы, үз аягым, кулым белән барлык эшемне башкаруым, табигатьнең матурлыгы, якыннарымның янымда булуы, калебемдәге Аллаһ биргән иман- барысы минем өчен бәхет. Аллаһка шөкер. Мине куп шөкер итүчеләрдән итсәң иде Раббым.* /Гөлчәчәк Габдрахманова/
  - *Шулай булса иде ул бу дөньяда. Намаз укучы динле хатын кызлар, аерылган бер бала белән калган булсада, бөтенесенәдә акча, байлык кирәк. Авылга кайтырга риза тугел. Намаз, Коръән укысада, аларга шәһәр, бай машиналы егет кирәк. Бәхетне саныйсыз, ә авылда кеше юк - бөтенесе шәһәрдә.* / Р. Тухфатуллин/

**2нче бирем “*Бәхетле булуны ничек күз алдына китерәсез?” дигән сорауга җавап эзләү***

- Ә сез кайсы фикер белән килешәсез? Чыннанда, бөтен кызларга акча гына кирәк микән, әллә яратуны өстен куючы кызлар бар бу дөньяда? /Укучыларның җаваплары/:

- Кайберәүләр бәхетне байлыкта, югары даирәдә йөрүдә, матур итеп киенүдә күрә. Ә бүтәннәр исә — үзенең сәламәт булуында, тыныч тормышта яшәвендә, гаиләле булуында. Мин икенче фикергә күбрәк тукталыр идем... Тигез канат астында, җылы гаилә учагында

дөрес тәрбия алып үсүләргә ни җитә?! “Мин бәхетлеме соң?” ...Әйе, әлбәттә, бәхетле! Чөнки минем әнием, гаиләм, җылы өем, дусларым бар!

- Минем фикеремчә, кеше бәхетне нидә күрсә, шуңа гомере буе омтылып яши торгандыр. Өлкәннәр очрашып үзара сөйләүче бәндәдә, кечкенәләр белән булганда да күп очракта сүзләрен сәламәтлек сорашып башлыйлар, шуны теләп төгәллиләр. “ Сәләмәт булсаң, бар да була”, - диләр алар. Бу күзәтүем мине “ бәхет ул - сәләмәтлектә” дигән фикергә килергә этәрде. Мин бәхетне сәләмәтлектә күрәм. Әгәр кеше сәләмәт булмаса үз хыялларын тормышка ашыра алмас иде.

- Безнең һәркайсыбызның бәхетле буласы килә. Без кешеләр арасында яшибез. Шуңа күрә тормышыбызда үзара мөнәсәбәтләрнең нинди булуы зур әһәмияткә ия. "Үзең яхшы булсаң, кеше дә яхшы, үзең начар - кеше дә начар" диелә татар халык мәкалендә. "Кеше кешегә көзге булып хезмәт итә" дигән әйтем дә бар. Димәк, башкаларның сиңа уңай мөнәсәбәттә булуын теләсәң, үзең яхшы күңелле кеше булырга тиешсең. Ә моның өчен үзеңдә матур сыйфатлар тәрбияләргә кирәк. (Бәхетле булу- ул хезмәтне ярату, намуслы, батыр, тугрылыклы, шәфкатьле, инсафлы булу.)

- /Укытучының нәтиҗәсе/:

- Нинди матур сүзләр! Болар һәр кешене бизи торган асыл сыйфатлар. Шәфкатьле булу – барлык күркәм гадәтләрнең башы, әдәплелекнең нигезе. Бары шәфкатьле бала гына бәхетле, тәүфыйклы, мәрхәмәтле, игътибарлы, кешелекле була ала.

- ***Интернет сайтларның берсендә, бәхет турында кеше фикере нинди микән дип караганда, мәнә нинди шигырь килеп чыкты:***

*Бәхетне без ничек анлыйбыз сон,*
*Кемнәр, кайсы җирдә куллана?*
*Минем очен бәхет- туган хәрбер көндә,*
*Таң нурлары белән башлана.*
*Ходай биргән гомер- ул зур бәхет*
*Тазалыгы белән бирелсә.*
*Шөкер итеп биргән барысына*
*Риза булып көнең курелсә.*
*Безне тапкан, назлап безне баккан,*
*Эти- эни исән булсалар.*
*Кайткан чакта туган нигезләргә*
*Капка ачып каршы алсалар.*
*Туганнарың тату булса- бәхет.*
*Уртак булса шатлык- кайгылар.*
*Куңелләрдә булса яхшы уйлар,*
*Таза булып туса сабыйлар!*
*Хәр нәрсәдән бәхет табып була,*
*Белу кирәк яшәу кадерен.*
*Тереләрне хөрмәт итә белеп,*
*Улгәннәрнен карыйк каберен.*
*Дөнья йорты- сынау йорты бит ул,*
*Кемнәр үзен ничек курсәтә.*
*Сынау биреп Аллаһ, сабырлыкка*
*Дөреслеккә безне өйрәтә.*
*Бар нәрәсәдә бәхет курә белсәк,*

*Сабыр калсак авыр чакларда,*
*Янәшәдә безнен Аллаһ булыр,*
*Жиңел булыр алга атларга.*
*Кадрия Камилова*

- Бу әсәрнең авторы бәхетне ничек итеп күз алдына китерә? /Укучыларның җаваплары/
- Минемчә, бәхетле булыр өчен Раббыбыз биргән нигмәтләргә шатланып яшәү, авырлыкларга сабыр итә белү, Аллаһ кушканча яшәү чын бәхеткә илтә.

**3нче бирем** ***"Әкият дөньясыда"***
- Бәхет турында әкиятне тыңлап китик. "Бәхет кемгә күбрәк елмая?" дигән сорауга җавап әзерлик.

**Бәхет**
(Корея халкы әкияте)

Бер авылда бик намуслы карт яшәгән, ди. Нәкъ төн уртасында төшендә үзенә күктән бәхет иңүен күрә ул. Икенче көнне, кырда эшләп йөргәндә, монаң китмәне нәрсәгәдер тиеп чыкылдап куя. Бераз казыгач, җир астыннан аждаһа, тавис кошы сурәтләре төшерелгән чүлмәк тартып чыгара. Төбендә кечкенә генә алтын тәңкә ялтырый икән. "Әгәр кичә төшемдә күргән бәхет булса, ул миңа күктән иңәргә тиеш иде, ә мин бу чүлмәкне җирдән таптым, - ди картю – Күрәсең, миңа тиешле бәхет түгелдер", - ди. Алтын тәңкәле чүлмәкне урынына куя да өенә юнәлә. Аның күршесендә генә бик к омсыз бай тора икән. Күршесенең хәзинәгә юлыгуын белгәч: "Җир бәхетеме, күк бәхетеме – барыбер түгелмени", - ди. Карт әйткән җиргә йөгереп бара, карый – хәзинәгә берәү дә кагылмаган. Чүлмәк эченә текәлсә шакката: еланнар, бакалар, төрле-төрле селәүчәннәр мыж килеп яталар икән анда.

- Ә-ә... Хикмәт менә нәрсәдә! Теге ахмак, дөньяда юкны сөйләп, намуслы кешеләрнең башын әйләндерә икән! Күрсәтим әле мин аңа! – ди икән бай. Чүлмәкне күтәрә дә китә күршесе йортына. Барып җитү белән, теге чүлмәкне тәрәзәгә томыра. Кешегә усаллык эшләүне уена да кертмәгән карт бу вакытта рәхәтләнеп йоклый икән. Нәрсәнеңдер чылтырап ватылуын ишеткәч куркып уяна. Күзен ачып җибәрсә, янәшәсендә зур гына чүлмәк!

- Ә менә монысы инде чыннан да күктән иңгән бүләк, монысы чыннан да минем бәхетем, - ди ул. Чүлмәкне караса, аның эче тулы алтын.
- Чыннанда, бәхет кемгә күбрәк елмая?
- Намуслы, комсыз булмаган, язмышына риза булган, күктән, ягъни Аллаһтан, килгән бәхеткә генә риза булган кешегә.

**4нче бирем.** ***Тест.***
(Тактада яки карточкаларда язылган).
***Бәхетне акчага сатып алып буламы?***
а) юк
б) әйе
в) җавап бирә алмыйм
***Кешенең үз бәхете үз кулында булуы белән килешәсезме?***
а) әйе
б) юк
в) җавап бирә алмыйм
***Нәрсә ул бәхет ?***
а) тазалык

б) гаиләң имин булу
в) яшисе килеп яшәү
г) һәр яңа көнгә сөенү
д) дусларың булу
е) ЕГЭны әйбәт  бирү
ж) ярату
з) тәмәке тартмау
и) аракы эчмәү
к) наркотик кулланмау
л) әйбәт билге алу
м) яхшы машинаң булу
н) дусларың булу
о) изгелекләрең күп булу
п) күңел тынычлыгы
р) Аллаһның синнән риза булуы

(Тестның нәтиҗәсен тикшерү, укучыларга җиткерү)

**V. Изге Коръән китабыннан**

- Аллаһ Тәгалә әйтте: ***«Мин җеннәрне һәм кешеләрне бары тик Миңа гына гыйбадәт кылсыннар өчен яралттым»*** *(“* Зәрият”: 56).

- Аллаһ Тәгалә безгә бу аяттә кешеләрнең бу дөньяда ни өчен яшәвен, ул кешеләрне нигә халык итүен, җиргә ни өчен шуның кадәр расулләр җибәрүен әйтә. Ул аларны бары тик бер максат белән генә яралткан: аның бер Үзенә генә гыйбадәт кылсыннар һәм Аны танысыннар, Аңа итагать итеп, әмерләренә буйсынып яшәсеннәр өчен. Әгәр дә кешеләр шушы аятьне аңлап, Раббыбыз Аллаһка буйсынып яшәсә, тыелганнарыннан тыелып, әмерләренә итагать итеп, ике дөнья бәхетенә дә ирешерләр иде. Бәхетсезлекнең төп сәбәбе менә шушы максатыбызны үтәп яшәмәүдәдер. Аллаһны танып, Ул кушканны үтәгән, Аның ризалыгына ирешкән кеше генә чын бәхетле була ала икән.

**VI. Хәдис**

- Мөхәммәд Пәйгамбәрнең хәдисен укып, аның турында үз фикерләрегезне әйтегез. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.с) әйтә:

- ***Инсаннар (кешеләр) җәмгыяте бер инсан тәнендәге әгъзаларга охшар. Тәндә булган әгъзалар бер-берсенә ярдәмче булып торулары, берсе эштән чыкса, башкалары да шуннан зарар күрүләре кебек, инсаннар да бер-берсенә ярдәмче булып торырга һәм берсенә килгән һәлакәтне башкалары да уртаклашып сызланырга тиешләр.***

- Мөселман кешесе бары тик башка мөселманнарны, аның тирәдә яшәгән кешеләрне бәхетле итә алса гына үзе бәхетле була алыр, чөнки үзе турында гына кайгыртучы кешене Аллаһ сөйми һәм дә аны бәхетле итми.

- Лилиана Ахметзянова, сезнең шикелле яшь кенә кыз, бәхетне болай күз алдына китерә:
*Бәхет ул, мөгаен, икәү бергә намаз укудыр,*
*Догаларда үз исемеңне ишетүдер...*
*Берең бик еракта булганда,*
*Аллаһ ризалыгы өчен яратканын аңлауда...*
*Йөрәк астында аның бер өлеше типкәнен тыңлауда,*
*Икәү бергә балага исем эзләүдә...*
*Күңелеңне тынычлыкта табып,*
*Чын мөселман кеше булуда. /Лилиана Ахметзянова/*

- Бу шигырьдә яшьләр өчен иң актуаль мәсьәлә- ярату турында сүз бара. Әммә ләкин Аллаһ ризалыгы өчен булган мәхаббәтнең иң зур бәхеткә китергәнне күрсәтә.

**VI. Рефлексия (Йомгаклау).**

- Ни өчен байлык, югары белем, начальник булу, хәттә сәламәтлек кенә бәхетле булу өчен җитми? (Байлык, югары белем, начальник булу, сәламәтлек кенә күңел тынычлыгын бирми.)
- Күңел тынычлыгын кайдан табарга мөмкин? (Рухи белемдә, үз- үзеңне тәрбияләүдә, башка кешеләрне бәхетле итүдә).
- Аллаһы Тәгаләне тануда, Ул кушканча яшәүдә, Аның ризалыгы эчен күп итеп изгелекләр кылуда.
- Димәк, нәтиҗә ясап шуны әйтә алабыз: бәхет- ул бүгенге көнеңдә канәгат булып, Аллаһы Раббызга шөкер итеп, җан тынычлыгы белән яши алуыбыз. Бәхетле бала шундый бала, кем бүгенге көненнән мәктәптә белем алуыннан, өйдә әти-әниләренең шатлыклы йөзләрен күрүдән, иптәшләре белән дустанә яшәүдән, кылган гамәлләреннән, игелекле эшләреннән тәм, ләззәт табып авыр вакытларда да сер бирмичә, шөкер итеп күтәренке күңел белән яши алучы баладыр.

**VI. Өйгә эш:**

1. “Бәхетле булу- Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алырлык итеп яши белүдә” дигән темага җавап әзерләргә.
2. “Мин үземнең бәхетле булуымны ничек итеп күз алдыма китерәм” дигән темага җавап әзерләп килергә.